ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 июнь, 2020 ел № 40/6

Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 463-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

## КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номеры Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/11, 2019 елның 25 февралендәге 30/6, 2019 елның 1 августындагы 32/11 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 6 пунктта:

– 37 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«37) тышкы мәгълүмат чарасы – биналарның, корылмаларның фасадларында, түбәләрендә һәм башка тышкы өслекләрендә (тышкы киртә конструкцияләрендә), шул исәптән витриналарны да кертеп, стационар булмаган сәүдә объектларының тышкы өслекләрендә, оешма яки шәхси эшмәкәрнең эшчәнлек алып бару урынында яки эшчәнлеген башкару урынында урнашкан, өченче затларга юридик затның исеме, юридик затның

эшчәнлек төре (тибы, профиле) турында мәгълүмат бирү максатларында мәгълүмат урнаштыру өчен билгеләнгән мәгълүмат конструкцияләре. Тышкы мәгълүмат чараларында шулай ук оешманың товар тамгасы яки хезмәт күрсәтү билгесе урнаштырылырга мөмкин;»;

- түбәндәге эчтәлекле 41 нче пунктча өстәргә:

«41) мәгълүмат табличкалары – «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Федераль законның 9 статьясы нигезендә урнаштыру мәҗбүри булган мәгълүмат, аерым алганда, оешманың фирма атамасы (атамасы), аның урнашу урыны (адресы) һәм эш режимы турында мәгълүмат, шулай ук закон буенча урнаштыру мәҗбүри булган яки эшлекле әйләнеш нәтиҗәсендә урнаштырылырга тиешле булган, реклама белән бәйле максатларны күздә тотмаган элмә такталар;»;

2) 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 бүлек. Гомуми таләпләр

7. Шәһәрнең бөтен территориясе һәм анда урнашкан барлык биналар (торак йортларны да кертеп) һәм корылмалар (алга таба - биналар, корылмалар) төзекләндерелергә, карап файдаланылырга һәм җыештырылырга тиеш.

8. Гомуми файдаланудагы территорияләрне, шул исәптән мәйданнар, урамнар, юллар, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, яр буе, скверлар, бульварлар, пляжлар, башка объектлар биләгән җир участокларын карап тотуны, җыештыруны вәкаләтле органнар үз вәкаләтләре чикләрендә оештыра.

9. Физик һәм юридик затлар, оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, милек, аренда һәм башка мәҗбүри хокуктагы (алга таба – җир участоклары хокукына ия булучылар) җир участогын һәм аңа чиктәш территорияне, шулай ук биналар, корылмаларны мөстәкыйль рәвештә яисә үз акчалары хисабына махсус оешмаларны җәлеп итү юлы белән карап тотуны һәм җыештыруны гамәлгә ашыралар.

9.1. Әгәр бина, корылма милек хокукында, яки башка әйбер, яки мәҗбүри хокукта берничә затныкы булса, җыештырылырга тиешле территория зурлыгы милек хокукындагы өлешкә яки күчемсез милек объектына башка хокукка пропорциональ рәвештә билгеләнә.

Әгәр җир участогы территориясендә төрле затларга караган берничә бина, корылма булса, территорияне карап тоту һәм җыештыру чикләре якларның килешүе белән билгеләнә ала.

Килешү булмаганда, җыештырылырга тиешле территория барлык милекчеләр яки башка биналарның, корылмаларның хуҗалары (файдаланучылары) арасында тигез өлешләрдә билгеләнә.

Физик яки юридик зат карамагында булган җир участогы билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән очракта, биләмәдәге җир участогының фактта барлыкка килгән чиге буенча, шулай ук чиктәш территория җыештырылырга тиеш.

Бина, корылма милек хокукында яки башка әйбер яки мәҗбүри хокукта берничә затныкы булган очракта, фасадны карап тоту якларның килешүе белән билгеләнергә мөмкин.

Килешү булмаганда, фасадны карап тоту милек хокукына яки күчемсез милек объектына башка хокук өлешенә пропорциональ рәвештә гамәлгә ашырыла.

9.2. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм җыештыру муниципаль заказны урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге төр эшләрне үткәрүгә конкурста җиңгән махсус оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9.3. Аерымланган трамвай юлларын, трамвайларны көтү тукталышларын карап тоту һәм җыештыру эксплуатация оешмалары тарафыннан башкарыла.

9.4. Шәһәр территориясе аша  уза торган тимер юллар, читләштерү полосалары, кичү юллары һәм юл аркылы чыгу урыннары чикләрендә әлеге корылмаларны эксплурацияләүче оешмалар көче белән  карап тотыла.

9.5. Күпфатирлы йортларның территорияләрен һәм алар янәшәсендәге территорияләрне  карап тоту һәм җыештыру күпфатирлы йортлар белән идарә итү ысулларының берсе нигезендә гамәлгә ашырыла: торак милекчеләре ширкәте яки торак кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы, идарәче оешма, күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау эшләрен башкаручы затлар – әлеге йортта биналарның милекчеләре белән турыдан-туры идарә иткәндә (алга таба-идарәче оешмалар).

9.6. Шәхси торак йортлар территорияләре һәм аларга янәшә территорияләрне карап тоту һәм җыештыру мондый йортларның милекчеләре (яллаучылар) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9.7. Яшелләндерү һәм төзекләндерү элементларын  карап тотуны гамәлгә ашыралар:

1) бирелгән җир участогы чикләрендә – җир участоклары милекчеләре яисә башка хокук ияләре;

2) гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр чикләрендә – муниципаль заказны урнаштыру нәтиҗәләре буенча эшләр башкаруга конкурс откан вәкаләтле орган яки махсуслаштырылган оешма;

3) чикләнгән файдаланудагы (предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр) һәм махсус билгеләнештәге (санитар зоналар, су саклау зоналары, зиратлар, питомниклар) яшелләндерелгән территорияләр чикләрендә – әлеге объектларның хуҗалары;

4) йорт янәшәсендәге территорияләр чикләрендә – күпфатирлы йортларда торак биналарның милекчеләре яки идарәче оешмалар.

9.8. Урам һәм юллардан грунт һәм өслек суларын бүлеп бирү өчен билгеләнгән кюветларны, торбаларны, дренаж корылмаларын җыештыру һәм чистарту, яңгыр канализациясе коллекторларын һәм яңгыр кабул итү коеларын чистарту эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан башкарыла.

9.9. Диспетчерлык пунктлары территорияләрен, шәһәр җәмәгать транспортының борылу мәйданчыкларын карап тоту һәм җыештыру шәһәр пассажир транспортын эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан башкарыла.

9.10. Җәмәгать транспортын көтү павильоннарын карап тоту һәм җыештыру муниципаль заказны урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен үткәрүгә конкурста җиңгән махсуслаштырылган оешмалар белән килешүләр нигезендә вәкаләтле территориаль органнар тарафыннан тәэмин ителә.

9.11. Җәмәгать бәдрәфләрен урнаштыру һәм карап тоту тәртибе гамәлдәге законнар, санитар кагыйдәләр һәм нормалар нигезендә билгеләнә.

Бәдрәфләрнең санитар һәм техник торышын аларның милекчеләре, хуҗалары, арендаторлары яки аларга хезмәт күрсәтә торган махсус оешмалар тәэмин итә.

9.12.Физик һәм юридик затлар тарафыннан шәһәр территориясен карап тоту һәм җыештыру чикләре бирелгән җир участогының чикләре (җир участогы билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән булса, милектәге җир участогының факттагы чиге буенча), биналарның һәм корылмаларның, алар эчендәге бүлмәләрнең милекчеләренең әлеге Кагыйдәләрнең 3.1 бүлеге нигезендә тирә-юньне төзекләндерүдә катнашу тәртибе нигезендә билгеләнә.

9.13. Вәкаләтле органнар, билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында, шәһәр территориясен, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне карап тоту һәм җыештыру буенча эшләрнең үтәлешен тикшереп торалар.

9.14. Муниципаль берәмлекнең гомуми кулланылыштагы территорияләрендә тыела:

1) территорияләрне металл, төзелеш, көнкүреш калдыклары һәм башка чүп-чар белән чүпләү;

2) төзелеш, көнкүреш калдыклары һәм башка чүп-чарны, махсус билгеләнгән урыннардан һәм чүп–чар җыю өчен контейнерлардан тыш урнаштыру;

3) билгеләнгән тәртипне бозып, стационар булмаган сәүдә объектларын, шулай ук ял итү өлкәсендә хезмәт күрсәтү объектларын (аттракционнар, кабартылган батутлар, велосипедлар, роликлар прокаты, халыкның ялын һәм күңел ачуын оештыру өчен кулланыла торган башка шундый объектларны) урнаштыру;

4) реклама-мәгълүмати материалларны яшел үсентеләргә (агачларга, куакларга һ. б.), су торбаларына, урам коймаларына, асфальт һәм плитка өслегенә һәм әлеге максатлар өчен билгеләнмәгән башка урыннарга урнаштыру;

5) махсус билгеләнгән урыннардан тыш урыннарда автомототранспорт чараларын юу һәм чистарту;

6) тиешле рөхсәттән (ордердан) башка җир эшләрен башкару;

7) грунт, төзелеш, көнкүреш калдыкларын һәм башка чүп-чар, кар, бозны шушы максатлар өчен билгеләнмәгән урыннарга чыгару һәм өю;

8) гамәлдәге законнарны бозып, урамнарда, тротуарларда, газоннарда төзелеш материалларын өеп кую, квартал эчендәге юлларны һәм йортларга керү юлларын ябу;

9) тәмәке төпчекләрен, кәгазьне, чүп-чарны газоннарга, тротуарларга, урамга, мәйданнарга, ишегалларына, паркларга, скверларга һәм башка җәмәгать урыннарына ташлау;

10) бакча диваннары, эскәмияләрнең аркасында утыру, чүп савытларын, урам утлары фонарьларын, башка кече архитектура формаларын пычрату һәм вату;

11) себерелгән чүпне, грунт, төзелеш, көнкүреш калдыкларын һәм башка чүп-чарны коеларның капкачларына, яңгыр канализациясенең су кабул итү рәшәткәләренә, лотокларга, кюветларга агызу;

12) төзелеш, көнкүреш калдыкларын һәм башка чүп-чарны, яфракларны һәм коры үләнне, тараны яндыру, учаклар кабызу, шул исәптән предприятиеләрнең һәм шәхси йортларның эчке территорияләрендә янгынга каршы чаралар күрмичә (ябык савытлар һәм янгын сүндерү чаралары булдырмыйча);

13) бу максатлар өчен билгеләнмәгән урыннарда урам сәүдәсе оештыру;

14) фасадларны рәхсәтсез үзгәртеп кору, барлык типтагы гаражлар урнаштыру, билгеләнмәгән урыннарда тышкы мәгълүматны чаралары, кече архитектура формалары урнаштыру;

15) яшел үсентеләрне сындыру, аларга зыян салу һәм юкка чыгару, кәүсәләрен кисеп, тамгалар ясау, аларга кадак кагу, гамак һәм таган, кер элү өчен баулар асу;

16) газоннарга зыян салу һәм аларны юкка чыгару;

17) транспорт чараларын яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннарны йөртү мәйданчыкларында, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштыру;

18) инженер-техник тәэмин итү челтәрләрен җир асты вариантыннан тыш һәм проект документларыннан башка төзү;

19) бу максатлар өчен бүлеп бирелмәгән җир участокларында рөхсәтсез транспорт чаралары кую урыннары төзү;

20) штендерлар урнаштыру»;

3) түбәндәге эчтәлекле 3.1. бүлеген өстәргә:

«3.1. бүлек. Чиктәш территорияләрне төзекләндерүдә җир участоклары, биналар, корылмалар ( алар эчендәге бүлмәләр) милекчеләренең яки башка хокук ияләренең катнашу тәртибе

9.15. Шәһәр территорияләренең тиешле санитар торышын тәэмин итү, әйләнә–тирә мохитне саклау һәм шәһәр территориясен пычратудан саклау чараларын гамәлгә ашыру максатларында хуҗалык итүче субъектлар һәм физик затлар каравына «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 19.4 статьясы нигезендә чиктәш территорияләр беркетелә.

9.16. Территорияләрне (җир участокларын) җыештыру, чистарту һәм санитар яктан карап тоту эшләрен башкару бурычлары гамәлдәге җир законнары, торак урыннар территорияләрен карап тотуның санитар кагыйдәләре нигезендә оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә, физик

һәм юридик затларга, әгәр законда яисә килешүдә башкасы каралмаган булса,түбәндәге тәртиптә йөкләнә:

9.16.1. Идарәче оешмалар – күпфатирлы йортларның йорт яны территориясе, шулай ук күпфатирлы йорт территориясе каршындагы җир участогы төп фасад ягыннан 5 м ара яисә урамның йөрү өлешенә кадәр 5 м дан да артык булмаган ара (объект юл буенда урнашкан очракта);

9.16.2. Күпфатирлы торак йортлардагы торак булмаган биналарны эксплуатацияләүче затлар – бинаның тулы озынлыгы буенча, киңлеге буенча – 10 м ара яки урамның (объект юл буенда урнашкан очракта) машиналар йөрү өлешенә кадәр 10 м артык булмаган ара, идарәче оешма белән килешү булмаган очракта;

9.16.3. Социаль өлкә учреждениеләре (мәктәпләр, мәктәпкәчә учреждениеләр, мәдәният, сәламәтлек саклау, физкультура һәм спорт учреждениеләре) – бирелгән җир участогы чикләрендә территория, шулай ук бирелгән җир участогы чигеннән 5 м ара яки урамның йөрү өлешенә кадәр 5 м дан да артык булмаган (объект юл буенда урнашкан очракта) территория;

9.16.4. Сәнәгать предприятиеләре һәм барлык милек рәвешләрендәге оешмалар – бирелгән җир участогы чикләрендә территория, аларга керү юллары, шулай ук бирелгән җир участогы чигеннән 10 м чиктәш территория, керү юллары;

9.16.5. Төзүче (подрядчы) – бирелгән җир участогы чикләрендә территорияләр, аларга керү юллары, шулай ук бирелгән җир участогы чигеннән 15 м янәшә урнашкан территория, керү юллары;

9.16.6. Торак йортларның хуҗалары – бирелгән җир участогы чикләрендә (җир участогы билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән очракта, җир участогының факттагы чиге буенча), шулай ук бирелгән җир участогына 5 м чиктәш яисә урамның машиналар йөрү өлешенә кадәр 5 м дан да артык булмаган (объект юл буенда урнашкан очракта) территория;

9.16.7. Стационар булмаган объектлар (лотоклар, киосклар, павильоннар һәм башка стационар булмаган сәүдә объектлары) һәм сезонлы кафелар хуҗалары – бирелгән җир участогы территориясе, шулай ук бирелгән җир участогына 10 м чиктәш яки урамның йөрү өлешенә кадәр 10 м дан да артык булмаган (объект юл буенда урнашкан очракта) территория;

9.16.8. Сәүдә һәм җәмәгать туклануы оешмалары (базарлар, кибетләр, рестораннар, кафелар) – бирелгән җир участогы чикләрендәге территорияләр, шулай ук бирелгән җир участогына 10 м чиктәш яки урамның машиналар йөрү өлешенә кадәр 10 м дан да артык булмаган (объект юл буенда урнашкан очракта) территория;

9.16.9. Биналарның, корылмаларның милекчеләре яки башка хокук ияләре – бина, корылма периметры буенча яки бирелгән җир участогының чикләре буенча, шулай ук бирелгән җир участогына 10 м чиктәш яки урамның йөрү өлешенә кадәр10 м дан да артык булмаган (объект юл буенда урнашкан очракта) территория;

9.16.10. Автомобиль юлларының юл буе полосалары чикләрендә урнашкан ягулык салу станцияләре, сәүдә һәм җәмәгать туклануы объектлары

– бирелгән җир участогы чикләрендә территорияләр, шулай ук бирелгән җир участогыннан машиналар йөрү өлешенә кадәр 15 м чиктәш территория;

9.16.11. Гараж кооперативлары – бирелгән җир участогы чикләрендәге территорияләр, аларга килү юллары, шулай ук бирелгән җир участогына 10 м чиктәш яисә урамның йөрү өлешенә кадәр 10 м дан да артык булмаган (объект юл буенда урнашкан очракта) территория;

9.16.12. Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек коммерцияле булмаган берләшмәләре–бирелгән җир участогы территориясе, шулай ук бирелгән җир участогына 10 м чиктәш яки урамның йөрү өлешенә кадәр 10 м дан да артык булмаган (объект юл буенда урнашкан очракта) территория;

9.16.13. Җирләү урыннары – бирелгән җир участогы чикләрендә, шулай ук бирелгән җир участогына 10 м чиктәш яки урамның йөрү өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта) территория;

9.16.14. Автотранспорт чараларын озак һәм кыска вакытлы саклау урыннарының хуҗалары–бирелгән җир кишәрлеге чикләрендәге территория, шулай ук бирелгән җир участогына 10 м чиктәш яки урамның йөрү өлешенә кадәр 10 м дан да артык булмаган (объект юл буенда урнашкан очракта) территория;

9.16.15. Коммуналь билгеләнештәге корылмалар булган оешмалар – бирелгән җир участогы чикләрендә территория, шулай ук бирелгән җир участогына 10 м чиктәш территория;

9.16.16. Автоматлаштырылган режимда эшләүче инженер корылмалары белән идарә итүче предприятиеләр (хезмәт күрсәтүче персоналдан башка) – бирелгән җир участогы чикләрендәге территория, шулай ук бирелгән җир участогына 10 м чиктәш территория;

9.16.17. Хезмәт күрсәтүче оешма – ике яклы төзелеш алып барылган урамнарда биләгән участокның озынлыгы буенча киңлеге буенча – магистраль тротуарга кадәр, тротуар булмаганда – урамның машиналар йөри торган өлешенең бордюр полосасына кадәр;

9.16.18. Хезмәт күрсәтүче оешма – бер яклы төзелеш эшләре алып барыла торган урамнарның озынлыгы буенча, киңлеге буенча – урамның бөтен киңлегенә, капма–каршы тротуарны да кертеп, 10 м тротуар артында;

9.16.19. Хезмәт күрсәтүче оешма – җир асты һәм җир өсте җәяүлеләр кичүләре өчен җир өсте өлеше, баскыч мәйданчыклары һәм чыгу урыннары периметры буенча 5 м арада;

9.16.20. Хезмәт күрсәтүче оешма – ерак рельстан ике якка да 1 м ара трамвай юллары өчен;

9.16.21. Хезмәт күрсәтүче оешма – шәһәр аша уза торган тимер юллар, читләштерү полосасы, сөзәклекләр, өслекләр, юл аша чыгу юллары һәм алар янәшәсендәге өлешләр чигендә –ике якка да 2 м ара.

Чиктәш территория гомуми файдаланудагы юл белән кисешкән очракта, территориянең зурлыгы юл бордюры яки тротуар бордюры белән кисешкәнчегә кадәр билгеләнә. Юл бордюры булмаганда, чиктәш территориянең зурлыгы гомуми файдаланудагы юл белән турыдан – туры кисешкәнчегә кадәр билгеләнә.

Ике һәм аннан да күбрәк объектның чиктәш территорияләре кисешкәндә, аларның факттагы зурлыгы әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән үлчәмнән кимрәк булганда, аларның үлчәмнәре объектлар арасындагы ераклыкның яртысы кадәр итеп билгеләнә.

Территория чикләре бер–берсенең мәйданына кергәндә (кисешкәндә) чиктәш территория объектлардан тигез ераклыкта билгеләнә.» ;

4) 120 пунктның 2 пунктчасында «урнаштыру» сүзеннән соң «һәм эксплуатация» сүзләрен өстәргә;

5) 120 пунктның 3 пунктчасында «урнаштыру» сүзеннән соң «һәм эксплуатация» сүзләрен өстәргә;

6) түбәндәге эчтәлекле 21.1 бүлеген өстәргә:

«21.1.бүлек Мәгълүмат табличкалары урнаштыру тәртибе

122.2. Мәгълүмат табличкалары әлеге мәгълүмат конструкциясендә мәгълүмат иясе булган оешма яисә шәхси эшмәкәр фактта урнашкан (эшчәнлек алып барган) бинаның, корылманың керү ишегенә, һәркем күрерлек итеп, фасадның архитектура элементларыннан буш булган яссы участокларында, турыдан–туры керү урынында (уң яки сул якта) урнаштырыла.

122.3. Бер объектта оешма, шәхси эшмәкәр өчен бер мәгълүмат табличкасы куелырга мөмкин.

122.4. Мәгълүмат табличкасы кыры җир өслегеннән (керү урыны идәненнән) 2 метрдан артмаска тиеш.

122.5. Мәгълүмат табличкасы фасад яссылыгы чикләрендә башка шундый ук мәгълүмат конструкцияләре булган бердәм горизонталь үзәктә урнаштырыла.

Мәгълүмат табличкасы мәгълүмат кырыннан (текст өлешеннән) тора.

Элмә тактаның рөхсәт ителгән зурлыгы:

киңлеге буенча 0,50 м дан артык түгел;

биеклеге буенча 0,60 м дан артык түгел.

Шул ук вакытта хәрефләрнең, билгеләрнең биеклеге 0,10 м дан артмаска тиеш.

122.6. Бер объектта берничә оешма, шәхси эшмәкәр урнашкан очракта, объект фасадларында бер керү урынында урнаштырыла торган мәгълүмат табличкаларының гомуми мәйданы 2 кв. метрдан артмаска тиеш.

Шул ук вакытта бер керү урынында урнашкан табличкалар параметрлары бертөрле булырга һәм 122.5 пунктының өченче абзацында билгеләнгән зурлыктан артмаска тиеш, җир өслегеннән (керү урыны идәненнән) мәгълүмат табличкасының өске ягына кадәр ераклык 2 м дан артмаска тиеш.

122.7. Мәгълүмат табличкалары витринаның пыяла өлешенә трафарет белән бастырылып урнаштырылырга мөмкин.

Шул ук вакытта күрсәтелгән табличкаларның озынлыгы – 0,30 м, биеклеге – 0,20 м дан артмаска тиеш.

122.6 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән очракта, витрина пыяласына берничә табличка урнаштыру рөхсәт ителә, табличкаларның

гомуми саны дүрттән дә артмаска, алар арасында ераклык 0,15 метрдан да ким булмаска тиеш.

122.8. Мәгълүмат табличкаларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнар таләпләрен үтәп урнаштырылырга тиеш.

Ике һәм аннан да күбрәк тел кулланылган очракта текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча тәңгәл килергә, дөрес һәм ачык итеп эшләнгән булырга тиеш.»;

7) түбәндәге эчтәлеге 126.1– 126.14 пунктларын өстәргә:

«126.1. Фасадларның өстәмә җиһазларына биналарны эчке эксплуатацияләүне техник тәэмин итүнең заманча системалары һәм биналар фасадларында урнаштырыла торган җиһаз элементлары керә.

Өстәмә җиһазларның төп төрләре:

1) кондиционерлау һәм вентиляция системаларының тышкы блоклары, шул исәптән вентиляция торбалары;

2) антенналар;

3) тышкы күзәтү видеокамералары.

126.2. Тышкы күзәтү камераларыннан тыш өстәмә җиһазлар урнаштыру архитектура биреме нигезендә Башкарма комитет яки ул вәкаләт биргән орган тарафыннан һәм биналарның милекчеләре ризалыгбашкарыла. гамәлгә ашырыла.

126.3. Бина фасадларына өстәмә җиһазлар урнаштыруга карата гомуми таләпләр:

1) кешеләрнең тормышы һәм сәламәтлеге куркынычсызлыгын тәэмин итү;

2) фасадның тышкы кыяфәтенә һәм техник торышына зыян китермичә, катгый билгеләнгән урыннарда урнаштыру;

3) аархитектура өслекләре белән минималь контакт, беркетүнең рациональ җайланмасы һәм технологик булуы, ныгытуның стандарт конструкцияләрен куллану;

4) җиһазларны комплекслы урнаштыру;

5) яшәү шартларына, җәяүлеләр һәм транспорт хәрәкәтенэ тискәре тәэсир ясамый торган итеп урнаштыру;

6) өстәмә җиһазларны эксплуатацияләү һәм аларга хезмәт күрсәтү уңайлылыгы.

126.4. Өстәмә җиһаз элементларын урнаштыру түбәндәге таләпләрне үтәгәндә рөхсәт ителә:

1) фасадның йөзлектән тыш өслегендә урнаштыру;

2) техник җайланмаларның фасад өслегенә минималь чыгуы;

3) компактлы итеп урнаштыру;

4) тышкы блокларны, детальләрне маскировкалау;

5) гомуми төп нигездәге кайбер элементларны төркемләү;

6) фасадта үзәк бердәм системасы бәйләнешендә урнаштыру.

126.5. Кондиционерлау һәм вентиляция системаларының тышкы блокларын урнаштыру рөхсәт ителә:

1) бина түбәсендә (бинаның түбәсендә урнашкан эчке һава–су каналлары булган кондиционерлар);

2) тәрәзә һәм ишек уемнарының өске өлешендә, фасад яссылыгы артына чыкмыйча, маскировкалау киртәләре (рәшәткәләр, жалюзи) ярдәмендә подвал кат тәрәзәләрендә;

3)ишегалды фасадларында – фасадларның бердәм үзәк системасына бәйләп;

4) лоджияләрдә, балконннарда, фасад нишаларында;

5) җир өслегеннән кимендә 3,0 м биеклектәге арка уемында.

126.6. Кондиционерлау һәм вентиляция системаларын тышкы блоктан башка, һаваны диаметры 0,15 метрга кадәр булган тишек аша бирерлек итеп, рәшәткә белән яшереп урнаштыру бөтен җирдә рөхсәт ителә.

126.7. Кондиционерлау һәм вентиляция системаларының тышкы блокларын урнаштыру рөхсәт ителми:

1) җәяүлеләр тротуарлары өстендә;

2) фасадның витражлы пыяласында;

3) фасад яссылыгыннан маскировкалау киртәләреннән башка чыгарлык итеп ясап, тәрәзә һәм ишек уемнарында;

4) биналарның шәһәр проспектларыннан һәм урамнарыннан күренә торган фасадларында, урнаштыру каралмаган урыннарда: Автозавод проспекты, Ак.Королев урамы, Аркылы ур урамы, Абдулла Алиш урамы, Әлмәт тракты, Авангардная урамы, Аэродром урамы, Габдрахман Әпсәләмов урамы, Автозавод проспекты, Гостев урамы, Виктор Поляков урамы, Фоменко урамы, Гагарин урамы, Гидротөзүчеләр урамы, Халыклар дуслыгы проспекты, Е. Н. Батенчук ис. урам, Вахитов ис. проспект, Габдулла Тукай исемендәге яр буе, Залесный проспекты, Муса Җәлил ис. проспект, Р.М. Низаметдинов ис.урам, Казан проспекты, Тынычлык проспекты., Мәскәү проспекты, Нариманов урамы, Яр Чаллы проспекты., Рәис Беляев проспекты, Раскольников урамы, Сөембикә проспекты, Сарман тракты, Хәсән Туфан проспекты, Чулман проспекты, Яшьлек поспекты.;

5) кондиционерның тышкы һәм эчке блогын тоташтыручы чыбыкларыннан еракта;

6) кондиционерның тышкы һәм эчке блогын тоташтыручы чыбыкларыннан еракта;

7) биналарның ябык (торец) фасадларында

126.8. Антенналар урнаштыру рөхсәт ителә:

1) биналар түбәсендә – бердәм нигезне кулланып компактлы тәртипкә китерелгән төркемнәр белән (кирәк булган очракта–коймалар белән);

2) урамнан күренми торган ишегалды фасадларында, стеналарда

аз катлы биналарда – бинаның архитектур күренешенә зыян китермичә

126.9. Антенналарны урнаштыру рөхсәт ителми:

1) фасадлар йөзлегендә

2) биналарның шәһәр проспектларыннан һәм урамнарыннан күренә торган фасадларында, урнаштыру каралмаган урыннарда: Автозавод проспекты, Ак.Королев урамы, Аркылы ур урамы, Абдулла Алиш урамы, Әлмәт тракты, Авангардная урамы, Аэродром урамы, Габдрахман Әпсәләмов

урамы, Автозавод проспекты, Гостев урамы, Виктор Поляков урамы, Фоменко урамы, Гагарин урамы, Гидротөзүчеләр урамы, Халыклар дуслыгы проспекты, Е. Н. Батенчук ис. урам, Вахитов ис. проспект, Габдулла Тукай исемендәге яр буе, Залесный проспекты, Муса Җәлил ис. проспект, Р.М. Низаметдинов ис.урам, Казан проспекты, Тынычлык проспекты., Мәскәү проспекты, Нариманов урамы, Яр Чаллы проспекты., Рәис Беляев проспекты, Раскольников урамы, Сөембикә проспекты, Сарман тракты, Хәсән Туфан проспекты, Чулман проспекты, Яшьлек поспекты.;

3) биналар түбәсендә, парапетларда, түбә киртәләрендә, вентиляция торбаларында;

4) фасадның почмак өлешендә;

5) балкон, лоджия киртәләрендә.

126.10. Торак һәм иҗтимагый әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларында өстәмә җиһазлар урнаштыру, аларның бина элементларына зыянлы йогынтысын бетерү шарты белән башкарылырга тиеш.

Кондиционерлау һем вентиляция системаларының тышкы блоклары, антенналар тәртип белән, фасадның архитектурасына һәм үзәкләрнең бердем системасына бәйле рәвештә, беркетү һәм аралауның (ограждение) стандарт конструкцияләрен кулланып, урнаштырылырга тиеш.

Кондиционерларның тышкы блоклары кондиционер эшләгәндә барлыкка килгән конденсат козырекларга, тәрәзәләргә эләкмәслек итеп урнаштырылырга тиеш.

Архитектура детальләрендә, декор элементларында, кыйммәтле архитектура бизәкләре белән эшләнгән өслекләрдә өстәмә җиһазлар урнаштыру, шулай ук архитектура өслегенә зыян китерә торган беркетү ярдәмендә урнаштыру да рөхсәт ителми.

126.11. Тышкы күзәтү видеокамералары асылмалар, козыреклар, балкон, эркерлар астында, фасад участокларында, архитектура детальләре һәм кыйммәтле, бизәкләү элементлары булмаган урыннарда урнаштырыла.

126.12. Колонналарда, фронтоннарда, кәрнизләрдә, пилястраларда, порталларда, козырекларда, балконнар янында тышкы күзәтү видеокамераларын урнаштыру рөхсәт ителми.

126.13. Фасадларда урнаштырылган өстәмә җиһазларның тышкы кыяфәтенә карата гомуми таләпләр булып тора:

1) унификация;

2) компактлы габаритлар;

3) заманча техник эшләнмәләр куллану;

4) югары декоратив һәм эксплуатация үзлекләренә ия булган материалларны куллану.

126.14. Өстәмә җиһазлар бинаның архитектура фонына максималь якын булган нейтраль төстә булырга тиеш.»;

8) 128 пунктта:

– 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3) мәгълүмат элементларын, биналарның (корылмаларның) фасадларын урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә Башкарма комитет тарафыннан бирелгән

килешүдән тыш бинаның (корылмаларның) фасадларына мәгълүмат табличкаларыннан тыш җайланмалар урнаштыру»;

– түбәндәге эчтәлекле 4–25 пунктчаларны өстәргә::

4) биналар (корылмалар) фасадларының өслегенә зыян китерү (пычрату): су агу, буяу кубу, ярыклар хасил булу, штукатурка кубу, тышлыгы кубу, кирпеч өеменең зарарлануы, тимер–бетон конструкцияләрнең саклагыч катламы кубу һ. б.;

5) биналарның һәм корылмаларның архитектура һәм сәнгать–скульптура детальләренә зыян китерү (проект документларында каралган булып, гамәлдә аларның булмавы): колонналар, пилястрлар, капительләр, фризлар, барельефлар, сылап ясалган бизү әйберләре, орнаментлар, мозаика, рәсемнәр һ. б.;

6) панельләр арасындагы кисешүләрнен герметизациясен бозу;

7) фасадларның, биналарның (корылмаларның) цоколь өлешендәге штукатурка, тышлау, буяу катламының зарарлануы (кубу, пычрану), шул исәптән тәрәзә, керү уемнары конструкциясенең төзек булмавы;

8) бина һәм корылма фасадларының чыгынкы өлешенә зыян китерү (пычрату): балконнар, лоджияләр, эркерлар, тамбурлар, кәрнизләр, козыреклар һ. б.;

9) балкон, лоджия, парапет киртәләрен җимерү (пычрату, аларның булмавы) һ.б.;

10) ясалма яшелләндерү;

11) мәдәни мирас объектларыннан кала, фасадлары белән гомуми файдаланудагы территориягә (шул исәптән мәйданнар, урамнар, юллар, яр буе, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе полосалары, скверлар, бульварлар) чыга торган биналар (төзелеш корылмаларыннан тыш) өчен территорияләрне койма белән әйләндереп алу өчен, бина, корылма фасадларын тышлау өчен профнастил, сайдинг, металл профильләр, металл листлар һәм башка шундый материаллар (күпфатирлы йортларның балконнары киртәләреннән, сәнәгать, склад, шәхси торак төзелешенән тыш) куллану;

12) җимерелгән яки зарарланган архитектура детальләрен төзәткәнче фасадны буяу;

13) фасадларны өлешчә бизәү (бинаның беренче катларын тулысынча бизәү искәрмә булып тора);

14) фасадның гомуми архитектурасына туры килми торган төсен, рәсемен, тышлык калынлыгын һәм башка элементларын, шул исәптән тәрәзәләрне һәм витриналарны, ишекләрне, балконнарны һәм лоджияләрне ирекле үзгәртү;

15) гамәлдәге козырекларны һәм түбәләрне бина һәм корылмаларның фасадларының декоратив матурлыгын һәм тышкы күренешен бозучы өстәмә элементлар һәм җайланмалар белән җиһазлау;

16) фриз урнаштыру, фасадны тоташтыру элементлары белән конструкциягә (каркас, стена, фасадка )тоташтырып тышкы яктан бизәү, шулай ук фриз, уозырек, бизәк төсенә туры килмәгән ныгытмаларны яшереп тоташтыру (планкалар, почмаклар, профильләр).

17) гомуми файдаланудагы территорияләргә чыгучы, алардан күренүче фасадлары булган биналарга һәм корылмаларга металл полотнолар урнаштыру, фасадның архитектурасына, характерына һәм фасадтагы башка керү ишекләренең төсенә туры килми торган ишекләр урнаштыру;

18) фасад яссылыгына карата уемда ишек блогының урнашу урынын үзгәртү;

19) тәрәзә һәм ишек тартмасы һәм уемы арасында фасадның тышкы кыяфәтен боза торган сыйфатсыз җөйләр ясау;

20) үтә күренмәлелекне ирекле үзгәртү, буяу һәм пыяла өслекләрне декоратив пленкалар белән каплау, пыялаларны пыяла блокларга алыштыру;

21) биналарның (корылмаларның) фасад, түбә, бина стенасы элементларыннан (төтен чыгу юллары, вентиляция, телевидение һәм радио коллектив кабул итү системалары антенналарыннан, чыбыклы радиотапшыру челтәрләренең баганалары, фронтоннар, козыреклар, ишекләр, тәрәзәләр, парапетлар, янгынга каршы баскычлар, җир асты элементлары һ. б.) элемтә линияләрен һәм һава–кабель чыбыкларын беркетү өчен файдалану;

22) тиешле рөхсәттән башка балконнар, лоджияләрдә нинди дә булса үзгәрешләр ясау, урамга чыга торган бина балконнарының тышкы ягында төп фасадларның лоджия һәм тәрәзәләренә келәмнәр, кием–салым, кер элү, шулай ук аларны төрле көнкүреш әйберләре белән томалау;

23) архитектура детальләрендә, декор элементларында, кыйммәтле архитектура бизәклəү өслекләрендә тышкы кондиционерлар һәм антенналар урнаштыру, шулай ук архитектура өслегенә зыян китерерлек итеп беркетү;

24) фасадның гамәлдәге декоратив, архитектура һәм сәнгать элементларын керү төркеме элементлары, керү төркемнәрен урнаштырганда яңача бизәкләү һәм реклама урнаштыру;

25) күпфатирлы йорттагы биналарның, корылмаларның милекчеләре ризалыгыннан башка, фасадларның архитектура, төс чишелешен, биналарның һәм корылмаларның декоратив–сәнгати бизәлешен үзгәртү;»;

9) 133, 134 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

10) 135 пунктның 3 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы 3 пунктчасы 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

3.Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак–коммуналь хуҗалыгын үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев